








# ФДББС таләпләре нигезендә татар телен укыту

Казан шәһәре Совет районы
“121 нче лицей”ның
татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Гарәфетдинова Алия Гомәр кызы

# Стандарт – гаилә, җәмгыять һәм дәүләт арасындагы иҗтимагый килешү.

## Гаилә

- Шәхси уңышлылык
- Социаль уңышлылык
- Профессиональ уңышлылык



## Җәмгыять

- Саклык  һәм сәламәтлек
- Азатлык  һәм җаваплылык
- Социаль  гаделлек
- Иркен тормыш, муллык

## Дәүләт

- Милли берлек
- Иминлек
- Кеше потенциалының үсеше
- Конкурентлыкка сәләтле булу

# Тормыш өчен белем алу

**Гомер буе белем алу**

# Башлангыч мәктәпне тәмамлаган укучының портреты

Укый белү нигезләренә ия

Мөстәкыйль, үз гамәлләре өчен җавап бирергә әзер

Туган ягын һәм Ватанын яратучы

Шәфкатьле, әңгәмәдәшчене тыңлый һәм ишетә белүче, үз позициясен дәлилли, үз фикерен әйтә алучы



Кызыксынучан, актив рәвештә тирә-юньне, дөньяны өйрәнә

Сәламәт тормыш алып бару кагыйдәләрен саклаучы

Гаилә һәм җәмгыять кыйммәтләрен хөрмәт итүче һәм

# Төп белем бирү программасын үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр

- **Шәхси**

Үзүсешкә әзер булу
Белем алуга һәм танып белүгә мотивация
Кыйммәтләр, мәгънәгә  ия булу
ижтимагый компетенция, шәхси сыйфатлар

- **Метапредмет**

Универсаль белем бирү гамәлләре:
Танып белү
регулятив
Коммуникатив

- **Предмет**

Аерым предмет фәненә кагылган эшчәнлек тәҗрибәсе
Фәнни белем элементларының системасы

ФДББС нигезендә тезелгән яңа программалар рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле укыту үз алдына түбәндәге максат һәм бурычларны куя:

а) укучыларда ана телен өйрәнү белән кызыксыну, аңа омтылыш уяту, үз милләтеңә һәм аның теленә мәхәббәт хисләре тәрбияләү;

ә) балаларда татар теленең барлык бүлекләре буенча мәгълүматлылык (компетенция) булдыру;

б) укучыларны өйрәнгән тел материалын урынлы файдаланып, татар телендә аралашырга өйрәтү;

в) телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру;

г) укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: *мәктәпне тәмамлаганда,* ***«укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”***.

Бу – яңа стандартта **эшлекле белем** дип атала**.** **Эшлекле белем** – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата.

# ФДББС буенча дәрес структурасы (төзелеше)

Федераль дәүләт белем бирү стандартлары кысаларында дәрескә әзерләнгәндә укытучы нәрсәләрне истә тотарга тиеш?

Иң беренче **дәрес этапларының конструкциясен** төзү мөһим.

1. Уку материалының темасы;
2. Теманың дидактик максаты;
3. Дәреснең дидактик максатының тибы;
4. Дәрес тибы:
   – яңа белемнәрне өйрәнү һәм беренчел ныгыту,
   – яңа белемнәрне ныгыту,
   – белем, осталык һәм күнекмәләрне комплекслы куллану,
   – белемнәрне гомумиләштерү һәм системалаштыру,
   – укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләрен тикшерү, бәяләү, төзәтмәләр кертү.

5. Дәрес структурасын уйлау;

6. Дәресне җиһазлау;

7. Уку материалының эчтәлеген сайлау;

8. Укыту методларын сайлау;

9. Педагогик эшчәнлекне оештыруның формаларын сайлау;

10. Белем, осталык һәм күнекмәләрне бәяләү;

11. Дәреснең рефлексиясе.

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Дәрескә әзерләнү | Укытучы дәрестә катгый структура нигезендә төзелгән конспектка таяна | Укытучы укытуның форма, алым һәм чараларын иркле сайлау мөмкинлеге тудырылган дәрес сценариясен файдалана |
| | Дәрескә әзерләнү барышында укытучы дәреслек һәм методик киңәшләрдән файдалана | Дәрескә әзерләнү барышында укытучы дәреслек һәм методик киңәшләрдән, интернет-ресурс, коллегаларының материалларыннан файдалана |

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Дәреснең төп этабы | Уку материалын аңлату һәм ныгыту. Күп вакытны укытучының сөйләме алып тора | Укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге (дәреснең яртысыннан артык вакыт) |

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Дәрестә укытучының төп максаты | Планлаштырыл-ганны үтәргә элгерү | Укучылар эшчәнлеген оештыру:<br>•мәгълүматны табу һәм эшкәртү буенча;<br>•эш алымнарын гомумиләштерү буенча;<br>•уку бурычларын кую һ.б. |

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Биремнәрне формалаштыру (укучыларның эшчәнлеген билгеләү) | Формулировка: *чиш, ашык, чагыштыр, тап, күчереп ал, эшлә һ. б.* | Формулировка: *анализла, дәлилләә, аңлат, чагыштыр, символлар белән күрсәт, схема яки модель төзе, дәвам ит, гомумиләштер, (нәтиҗә ясa), сайла, үзгәрт, бәялә, уйлап тап һ. б.* |

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Дәрес формасы | Күбесенчә (нигездә) фронталь | Нигездә группалап һәм индивидуаль укыту |

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Укучыларның ата-аналары белән үзара йогынты | Лекция формасында үтә, ата-ана белем бирү процессында катнашмый | Укучыларның ата-аналары мәгълүматлы. Аларга белем бирү процессында катнашу мөмкинлеге тудырылган |

# ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
| --- | --- | --- |
| Белем бирү тирәлеге (мохите) | Укытучы билгели. Укучылар эшенең күргәзмәсе | Укучылар тарафыннан билгеләнә (укучылар укыту материалын әзерли, презентацияләр үткәрә). Класс, холл зонын куллану |

## ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлегендәге үзгәрешләр

| Үзгәреш предметы | Укытучының традицион эшчәнлеге | ФДББС буенча эшләүче укытучы эшчәнлеге |
|---|---|---|
| Укыту нәтиҗәсе | Предмет нәтиҗәләре | Предмет, метапредмет һәм шәхси нәтиҗәләр |
| | Укучының портфолиосы юк | Портфолио булдырыла |
| | Төп бәяләү – укытучы бәяләмәсе | Укучының үзбәяләмәсенә ориентлашу, адекват үзбәя формалаштыру |
| | Контроль эшләр буенча уңай билгеләр мөһим | Нәтиҗәләр динамикасын истә тоту мөһим. Арадаш нәтиҗәне бәяләү. |

# Технологияләр

- үстерелешле укыту;
- проблемалы укыту;
- критик фикер йөртү сәләтен үстерү технологиясе;
- төрле дәрәҗәдәге укыту;
- укытуның тикшеренү методлары;
- проект методлары;
- “дебат” технологиясе;
- модульле укыту;
- укытуда уен методларын куллану: рольле, эшлекле һ.б.
- хезмәттәшлек технологиясе;
- информацион-коммуникатив технологияләр;
- сәламәтлекне саклау технологияләре;
- инновацион “потфолио” бәяләү системасы;
- дистацион укыту технологиясе

һ.б.

Укытучы тарафыннан дәресне нәтиҗәле итеп оештыру өчен нәрсәләргә игътибар итү сорала:

– аеруча уңышлы дип табылган дифференцияләшкән һәм шәхси укытуга юнәлдерелгән, кызыксынуны арттыра торган һәм иҗади активлыкны үстерә торган укыту методларын, эффектлы алымнарны сайлау, уйлап табу;

– үзконтрольлекне оештырып эшчәнлекне башкару (дәреснең планын педагогик принциплардан – эзлеклелек, оптимальлек, кешелеклелек, гуманитарлылыктан чыгып коррекцияләү);

– булачак дәреснең план-сценариясен (технологик картасын) төзү.

Дәрестә укучының игътибарын даими җәлеп итеп тору алымнары:

– проблемалы ситуацияләр булдыру;
– укучыларның белем үзләштерү темпларын үзгәртеп тору (тизләтү яисә әкренәйтү);
– укучыларга көтелмәгән, кызыклы сораулар хәзерләү;
– белем бирү процессында аудио-, видео техник чаралар- ны, күрсәтмәлелекне куллану;
– фронталь, төркем белән эшләү төрләрен актив чират- лаштырып тору;
– дәрестә төрле кызыклы ситуацияләрне мисал итеп китерү;
– уңышлылык халәтен тудыру;
– дәрес эчтәлегенә төрле уеннарны кертеп җибәрү;
– көч сынашу-узышуга корылган биремнәрне бирү;
– укучылар белән ышанычлы әңгәмә-диалог кору.

# Уку уңышларын бәяләү

| Теманы өйрәнү этабы | Диагностика төре | Максат |
|---|---|---|
| Теманы өйрәнә башлау | Старт диагностика | Әзерлек дәрәҗәсен билгеләү, яңа материалны өйрәнүгә булган мотивацияне ачыклау |
| Теманы өйрәнү барышы | Агымдагы диагностика | Укучыларның индивидуаль прогресс (алгарыш) дәрәҗәсен бәяләү |

**Укытучының профессиональ бурычы –**

**укучылар канәгатьлек алырга тиеш!**